СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 296 26.02.2015

№ _________от ______________

# КАРАР

Авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы составына керүче Арташ, Олы Кибәче, Олы Нырты, Олы Шыңар, Югары Симет, Явлаштау, Эзмә, Килдебәк, Курсабаш, Мишә, Мичән, Түбән Шытсу, Сатыш, Иске Икшермә, Тимершык, Шекше, Юлбат авыл җирлекләре Советлары тәкъдимнәрен кабул итәргә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләрен әлеге җирлекләрнең Башкарма комитетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча тапшыру турында:

– җирлектә яшәүчеләрне һәм аз керемле гражданнарның торак урыннарына мохтаҗларны торак урыннары белән тәэмин итү;
– торак төзелеше өчен шартлар тудыру;
– муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру;
– муниципаль торак фондын исәпкә алу;
– гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм аларга муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган керем күләмен һәм гаилә әгъзалары милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү;
– гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемен һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләренең

хакын билгеләү;

– гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен билгеләү;

– социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак гражданнарны билгеләнгән тәртиптә исәпкә алуны алып бару;

– социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алуны алып бару;

– муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре буенча билгеләнгән тәртиптә аз керемле гражданнарга бирү;

– муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру;

– җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм парковкалар (парковка урыннары) төзүне һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүне дә кертеп, аларда юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү;

– җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

– гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юллары исемлеген, гомуми булмаган файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юллары исемлеген раслау.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетына:

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының авыл җирлекләре Башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында, төзелүче килешүләрнең гамәлдә булуы 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын исәпкә алып, килешү төзергә;

– Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты турында» 2014 елның 19 декабрендәге 278 номерлы Саба муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы карары проектын бюджет законнары нигезендә Саба муниципаль районы Советына әзерләргә һәм карауга кертергә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р.М. Гасыймовка йөкләргә.

Саба муниципаль
Башлыгы Р.Н. Минниханов